# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЮГАРЫ КИБӘХУҖА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

## КАРАР

**Чираттантыш утырыш дүртенче чакырылыш**

**20.10.2023ел** **№104** **Югары Кибәхуҗа авылы**

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Югары Кибәхуҗа авыл җирлеге Советының 10.06.2016 ел №22 «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Югары Кибәхуҗа авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәне раслау хакында» карарына үзгәрешләр кертү турында

«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 28 сентябрендәге 86-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Теләче муниципаль районы Югары Кибәхуҗа авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Югары Кибәхуҗа авыл җирлеге Советының 10.06.2016 ел №22 «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Югары Кибәхуҗа авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәне раслау хакында» карарына (10.05.2017 №39, 19.06.2017 №42, 25.12.2017 №58, 20.12.2018 №98, 11.02.2019 №99, 11.09.2019 №110-1, 12.03.2021 №15, 15.11.2021 №41, 10.03.2022 №51, 17.01.2023 №81, 18.08.2023 №96 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- күрсәтелгән карар белән расланган, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Югары Кибәхуҗа авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә:

А) 19 бүлектә:

- 5 өлешне «, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш,» сүзләре белән тулыландырырга;

- 7 өлешне «, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш,» сүзләре белән тулыландырырга;

Б) 23.1 бүлекне түбәндәге эчтәлекле 1.1 өлеш белән тулыландырыга:

«1.1. Муниципаль хезмәткәр «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законда, коррупциягә каршы тору максатларында башка федераль законнарда билгеләнгән бурычларны үтәмәгән өчен чикләүләрне һәм тыюларны, мәнфәгатьләр конфликтларын булдырмау яисә җайга салу турындагы таләпләрне үтәмәгән өчен җаваплылыктан азат ителә,

әгәр мондый чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәмәү, шулай ук мондый бурычларны үтәмәү «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законның 13 статьясындагы 3 - 6 өлешләрендә каралган тәртиптә аңа бәйле булмаган хәлләрнең нәтиҗәсе дип танылса».».

2. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

3. Әлеге карарны гамәлдәге законнар нигезендә бастырып чыгарырга.

Югары Кибәхуҗа
авыл җирлеге башлыгы Ф.Р. Мәхмүтов